*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп белем бирү мәктәбе*




# Классташлар



*Октябрь 2013 ел*




Гүзәлләрдән гүзәл сезнең йөрәк.
Игелек бирәсез һәркемгә,
Ашыгасыз бәхет өләшергә,
Һәр иртәдә безгә, һәр көндә








# Котлыйбыз!

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Keче Кибәхуҗа төп белем бирү мәктәбенең директоры һәм математика укытучысы Әхмәтҗанова Найлә Нуретдин кызының 7 октябрьдә туган көне.**

## Хөрмәтле Найлә Нуретдиновна!

**Сезне чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә сәламәтлек, хезмәт уңышлары, балалар бәхете, озын гомер телибез.**

**Халкыбыз җәүһәрләре булырдай**
**Шәхесләр бу җирдә житәрлек.**
**Сезгә дә тумыштан бирелгән**
**Тырышлык, акыл һәм зирәклек.**
**Вөждан күзе белән карыйсыз Сез**
**Тормыштагы һәрбер мизгелгә.**
**Күпме изге гамәл энҗе булып**
**Гомер юлыгызга сибелә.**
**Саф алтын күгәрми беркайчан,**
**Онытылмый мәңгегә изгелек.**
**Телибез бәйрәмдә зур саулык,**
**Бетмәс көч, бәхет һәм иминлек.**

***

8 сыйныф укучысы Шәнгәрәев Рушанның -5 октябрь,
**2 сыйныф укучысы Мөхәммәдиева Сиринәнең - 12 октябрьдә,**
**5 сыйныф укучысы Белозерова Диләфрүзнең - 21 октябрьдә,**
**Заһидуллин Рәсимнең -** 22 октябрьдә туган көннәре.
Туган көнегез белән котлап
Бәхет телибез сезгә, дуслар.
Иңнәрегезгә бары изге
Фәрештеләр генә кунсын!






# “Сәләтле балалар үсүенә шатмын...”-

дип билгеләп үтте җәмәгатьчелек белән элемтә хезмәте җитәкчесе Гүзәлия Минкина.

**“Җир – безнең туган йортыбыз” дигән иншалар конкурсында катнашкан укучыларның иншаларыннан эзекләр.**



***“Табигатьне күз карасы кебек саклыйк, дуслар!”***

Гыйльметдинова Л.

***“У нас не горят факелы с месторождений природного газа. Нет скважин выкачивания нефти, и не остаются под землей пустоты, но возле моей маленькой речки зачастую можно увидеть свалку мусора... Горькими слезами плачет природа”.***

***Серапионов А.***



***“Любить Родину – значит беречь ее”***

***Гильмутдинова Г.***

***“Мин ел саен әнием белән Әҗикә чишмәсен чистартырга йөрим”***

***Рахматуллина Э.***





***“ Без прошлого нет настоящего”***

***Гимадиев И.***



***«Нет на земле краше моего родного края. Беречь его - мой и твой долг!»***

***Аскарова А.***



## 1 октябрь – Өлкәннәр көне

## *Әле дә ярый сез бар дөньяда.*




***Әбекәем.***

Синең көләч, нурлы йөзең һәрчак
Сөендерә мине.
Син авырсаң, сагышлансаң әгәр –
Көендерә мине.
Яшәвеңне тою, әбием булу –
Нинди олы шатлык!
Мәңге яшә, әбекәем минем,
Килмә әле, картлык!

**Закиров Ф.6 сыйныф**

***Әбием***

Безнең әби – “во”әби!
Без аны яратабыз
Ни өчен? -дип сорасагыз,
Без хәзер аңлатабыз.
Назлап сөеп, бәбкәм, дия,
Ни сорасаң шуны бирә.
Мәктәптән кайтуыма
Тәмле ашлар пешерә.
Тәмле итеп ашата да:
“Ятып тор, арыгансың, ди,
Ничә дәрес керде бүген?
Сумкаң шундый авыр”,-ди.
Минем хәлгә керә белә,
Елаганда юата.
Әгәр аврып китсәм,
Борчыла ул, жан ата.
Минем төрле сорауларга
Җавапны бик тиз таба.
Ышанмыйсызмы?
Безгә килеп кара.
Безнең әби – “во” әби!
Юк белмәгән эше дә.
Исән әле аның
Һаман 32 теше дә.

**Шәйхетдинов Ф. 6 сыйныф**

***Минем әбием***

Яратам мин әбиемне
Җанга якын булганга.
Ул бәйләгән оекб**ашлар**
Ирек бирмәс туңарга.

**Гыйльметдинова Г. 3 сыйныф**

***Бергәләп***

Мин әбине бик яратам,
Ул да мине ярата.
Без аның янына килгәндә
Тәмле чәен кайната.
Без чәйләр өчеп киткәч
Савыт-саба юабыз.
Әбиемнең өйләрен
Ялт иттереп куябыз.

**Рахматуллина Э.5 сыйныф**

# *Беслан трагедиясе безнең йөрәкләребезне һаман борчып тора*







**3 сентябрь 2004 ел**

## ***Әлеге терактта 334 кеше һәлак булды. Шуларның 186 сы балалар иде...***

## *Хәтер яктысында*

Сугышның соңгы залплары тынуга да 70 ел тула. Әмма халкыбызның яу кырында һәм тылда күрсәткән фидакарьлеге һәркемнең йөрәгендә. Яудан кайтмый калганнарның язган хатларына, выкытлар үтү белән саргайган рәсемнәренә дә,сөйләгән сүзләренә кабат-кабат кайтырбыз әле.

Тарихта тиңе күрелмәгән бу сугыш афәте турында уйлыйсың да бүгенге имин көннәрен кадерен, аларның нинди югалтулар хисабына яулап алынганлыгын ныграк аңлыйсың. Сугышларсыз, тыныч тормышның озак, бик озак дәвам итүен телисең.

Һәр ел, яз җитүгә, Җиңү бәйрәме килә. Тормыш дәвам итә. Ләкин, юк дисәк тә, әле монда, әле тегендә ут чыгып тора. Кайнар нокталар дип исемен үзгәртсәк тә – ул шул ук сугыш, шул ук үлем, аналарның мәңге кипмәс күз яшьләре.

Булмасын иде сугышлар. Бүген дә, иртәгә дә, аннан соң да, өйләрдә гөрләп туйлар узсын, дөньяга сабыйлар туып торсын. Һәркайсы әти-әниле булсын!

Рахматуллина А.Ә.тарих укытучысы.

Моннан 6 ел элек, ул вакытта 5 сыйныфта укыган Гыйниатуллин Рәсүлнең иншасыннан өзек.

“Рус теле дәресендә укытучы апа өй эше итеп инша язарга бирде . Ул миңа: “Рәсүл, син бабаң турында яз. Син бит – герой бабай оныгы. Синең истәлекләрең дога булып ирешер” ,-диде.

Герой бабай оныгы?! Уйга калдым. Моннан бер ничә ай элек дөнья куйган бабаем күз алдыма килеп басты. Минем дәү әтием – Гыйниятуллин Гарифулла. Ул герой булмаганмыни? Булган, әлбәттә.

Дәү әтием Ленинград фронтында алгы сызыкта сугыша. Дүрт ел ут астында фашистлар белән күзгә-күз очраша.

Көчле бәрелешләрнең берсендә бабам каты яралана. Дошман пулясы аның кулын һәм аягын яралый. Тәне тулы ядрә. Аннан соң тормышы сәламәтлек өчен көрәштә үтә. Хәрби госпиталь... Озак дәвалана бабам.

1944 елның ахырында ул, хәрби хезмәткә яраксыз булып, туган авылына Олы Кибәхуҗага кайта. Яңадан авыр тормыш. Сугыштан соңгы еллар...Ачлык...Бу авырлыклар да көчле рухлы бабамны сындырмый. Ул тормыш корып, авылда яши башлый. Хезмәткә сусап кайткан бабам, нинди авыр эш бар, шуңа тотына. Тормыштан тәм табып, аның кадерен белеп яшәде ул. Сугыштан исән-имин кайтуына шатлана иде ул.

Ул безне һәрвакыт яхшылыкка, кешеләргә игелекле булырга өйрәтте. Аның “Акыллы бул, улым”, дигән сүзләре һаман да минем колагымда яңгырап тора.

# *Укырга кая керергә?*



Алга куйган максатыбыз җиңелләрдән түгел: медицина университетына укырга керергә! Нинди каршылыклар буласын алдан ук чамалар өчен, тәҗрибәле кешене педиатрия факультетының II курс студенты Нигъмәтҗанова Ләйсәнне ярдәмгә чакырдык.

Ләйсән сүзләренә караганда, медицина университетында башка вузлардан аермалы буларак, иң беренче кыенлык психологик киеренкелек икән. Чыннан да, беренче курстан ук, “анатомичка”дагы дәресләргә йөрергә кирәк! “Анатомичка – кешенең анатомиясен “тере” (үле) материалда өйрәнү максатында, мәетләрнең ярып карый торган лаборатория инде ул. Икенче курстан башлап, ассистент ролендә операцияләргә керә башлыйсың. Мондый операцияләрдән соң кайбер хисчән студентлар һуштан язып егылырга мөмкин.

Студент-медиклар беренче еллардан ук сырхауханәләрдә практика уза. Соңрак үзләренә бер авыру беркетәләр, авыру тарихын язу, дәвалау тулысынча аларга тапшырыла (моның өчен билге куела).

Беренче курстан башлап, латин теле укытыла. Барлык врачлар да бу телне белергә тиеш,чөнки рецептлар латинча языла бит. КДМУда корыч дисциплина , биредә дәресләрдән качып йөри алмыйсың. Тагын бер проблема: укыту бары тик рус телендә генә алып барыла. Башта татар милли мәктәбен, аннан Теләче мәктәбен тәмамлаган Ләйсәнгә, мәсәлән, баштарак кыенга туры килгән. Менә шулай безне Ләйсән куркытып та бетерде бугай инде. Анда укуның яхшы яклары бармы соң, диярсез. Әлбәттә! Беренчедән, чит илләр белән ныклы бәйләнеш тоталар. Тагын кайсы вузда мондый эчтәлектәге белдерүгә юлыгырсың: “Практиканы чит илдә үтәргә теләгән студентлар игътибарына! Бельгия, Венгрия, Польша, Словакия, Мисыр, Мальта, Греция, Төркия, Югославиядә өстәмә урыннар тәкъдим ителә”.

“Дүрт татар” КВН командасының да бездә оешканлыгын онытмагыз, - ди Ләйсән. 15 май – университетның туган көне. (Казан университетында медицина факультеты ачылган 1814нче ел безнең вузга нигез салынган чак дип исәпләнә). Июнь аеның икенче якшәмбесендә Медицина хезмәткәрләре көнен бәйрәм итәбез. Ничек дисезме? Тантаналы төстә имтиханнар тапшырып! Чөнки бу вакытта сессия була.

Биредә 7 факультет бар. Педиатрия (6 ел укырга), дәвалау, медицина-профилактика, стомотология, фармакология (5әр ел), менеджмент һәм югары шәфкать туташы белеме һәм социаль медицина факультеты. (4ел). Югары шәфкать туташы белемен алу өчен, башта урта махсус медицина белеменә ия булу сорала. Күпчелек факультетларга имтиханнар түбәндәгечә: химия (БДИ), биология (БДИ), рус теле (ЕГЭ), Социаль факультетка керү өчен – җәмгыять белеменнән (БДИ), югары шәфкать туташы факультетына социаль гигиена һәм сәламәтлекне саклау буенча да имтиханнар өстәлә.

Иң әһәмиятлесе – укырга дигән ныклы максатыгыз булсын. Башка вузларда кебек ук, биредә дә махсус әзерлек курслары эшли. Якшәмбе дәресләренә 9нчы октябрьдән языла була, укулар ноябрьдан башлана. Предметлар – химия, биология.

Кичке курсларга 3нче январьдан язалар, укулар февральдән башлана. Предметлар – химия, биология, җәмгыять белеме, социаль гигиена һәм сәламәтлек саклау.

Барлык институтларда зачет, имтихан расписаниеләрен сессия җиткәнче диярлек көтсәләр, медуниверситетта бөтен уку-укыту планы инде сентябрьда ук белдерүләр тактасына эленеп тора. Шундый тәртип инде!

**Укырга керергә җыенган һәр егет-кыз өчен девиз: киләчәгең хакына син тырышырга тиеш!**


Форсаттан файдаланып, барлык Кече Кибәхуҗа төп белем бирү мәктәбе укытучыларына рәхмәт әйтәсем килә, сезгә сәламәтлек, гаилә бәхете, эшегездә зур уңышлар теләп калам!

Хәдичә Нургалиевна Ләйсән ярдәмендә “укырга керде”.

## Уяндыңмы, елмай!

...көнне башла шулай.

Иркәләп-назлап йокыңнан уятучы әниеңә елмай. Әтиеңә елмаеп кара. Кичтән юк сәбәпне бар итеп тиргәп ташлаганнар иде, дисеңме? Дәресләреңне әзерләмәгән көе уйнарга чыгып чапма, дип кенә әйттеләр бит алар сиңа. Аннары кич буе компьютерда утырма, дип кисәттеләр, күрше кызын кемнең үртәп елатуы турында сорадылар. Ник болар берсе дә дөрес түгелмени? Ә син турсаеп йөрмә, иртән торышына елмай да, өйдәгеләрнең һәммәсенә хәерле көн телә. Кичәге хаталарны бүген кабатламам, дигән сүз була инде бу. Әти-әниең эшкә әйбәт кәеф белән чыгып китәр, елмаеп башлаган көн синең өчен мәктәптә дә матур дәвам итәр. Тик... елмаюың ямьсез көлүгә генә әйләнмәсен! Өлкәннәрнең дә, классташларыңның да кәефен төшерә торган мыскыллы көлүләр нигә кирәк? Андый гамәлләр бумеранг кебек – кайчан да булса тагын да ямьсезрәк булып үзеңә әйләнеп кайта бит ул! Көнеңне елмаеп башла! Бүген дә, иртәгә дә. Аннан соң да. Елмаеп-көлеп яшәрлек сәбәпләр генә күбрәк булсын, берүк.



# 15 октябрь – Корбан бәйрәме

## Г.Тукай “Таян Аллага”

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!
Йа Ходай, күрсәт, диген ошбу җиһанда якты юл;
Ул рәхимле; әткәең-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул! Саф әле күңлең синең, һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән. Пакъ җаның һәм тәнең – барлык вөҗүдең пакъ синең; Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең! Кыйл дога, ихлас белән тезлән кыйла каршына; Бел аны: керсез күңелдән тугъры Юл бар гаршенә!
Әй бәхале, әй кадерле, әй гөнахсыз яшь бала! Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

**Элек безнең әби-бабайлар дин кушканча яшәгәннәр. Укымышлы булганнар. Җәйге челләдә дә (аларга булышырга хәзерге кебек техника да булмаган бит!) биш вакыт намазларын да калдырмаганнар. Халкыбызның шушы сыйфатларын күздә тотып һәм аларны дәвам итү максатыннан, бүген без сезгә Аскаров Данис белән әңгәмәбезне тәкъдим итәбез.**

-Данис, синең өчен иң бөек китап нәрсә ул?

-Минем күңелдә тирән эз калдырган китап – Коръән Кәрим. Коръәндә Аллаһы Тәгаләнең сүзләре язылган. Аны аңлау өчен куп укырга кирәк. Коръәндә кешенең туганнан башлап үлгән көненә кадерге тормыш юлы, ничек яшәргә, үз-үзен ничек тотарга, баласын ничек тәрбияләргә тиешлеге турында язылган.

- Дин юлына кереп китүеңә нәрсә этәргеч булды?

- Ислам диненә кереп китүемә Рамил хәзрәт һәм әтием этәргеч булдылар дип уйлыйм. Әти мине кечкенәдән мәчеткә алып барды. Минем мәчеткә йөрүемне әти-әни дә хупладылар “Улым өйрән. Ислам дине начарлыкка йөрәтмәс!”-диделәр.

- Данис, дин нәрсәгә өйрәтә?

-Ислам дине мине догалар укырга, тату яшәргә, бүтәннәр белән яхшы мөгамәләдә булырга, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга чакыра.

-Уразаны әти-әниең белән тотасыңмы?

-Әни белән бергәләп тотабыз. Әти дә киләчәктә кушылыр дип өметләнәбез.

-Үзеңнең иптәшләреңә ниләр теләр идең?

-Кайберәүләрнең тәнкыйтьләүләренә, сәер карашларына игътибар итмичә, Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, аңа гыйбәдәт кылып, тыйганнарыннан тыелып яшәргә кирәк. Дин юлын сайласагыз, сез беркайчан да начар юлга басмассыз дип ышанып әйтергә була.

Сезгә алларыгызда торган авырлыкларны җиңеп чыгарга, һәр көнгә сөенеп, шөкер итеп яшәргә Аллаһы ярдәм итәр, көч бирер.

- Данис, минем сорауларга җавап биргән өчен зур рәхмәт, сиңа һәр бер эшеңдә Аллахы Тәгалә ярдәм бирсен.

-Амин.

Данисның сүзләрен Арсланова И.М. язып алды.

## *Олимпиаданы каршылап*

## Гыйльметдинова Гөлшат: мин абыйларым кебек буласым килә.

-Гөлшат, синең уңган кыз икәнлегеңне беләм, алай да, өйдә яратып эшләгән эшләрең бармы?

-Мин өй җыештырырга, идән юарга, мал карарга яратам. Һәр эштә әнигә булышырга тырышам.







-Гөлшат, менә мин Айдар абыеңның 30лап Мактау грамотасын, И.Низамовның ике Рәхмәт хатын, күп кенә медальләрен тотып торам. Азат абыең да аңардан ким түгел. Икесен дә спортсменнар дип әйтеп була. Син әле генә спорт белән шөгыльләнә башладың. Нәрсә этәргеч бирде?

-Кечкенәдән абыйларымның спорт белән шөгыльләнгәннәрен күреп үстем. Айдар абыем һәр иртәдә йөгереп кайтты, салкын су белән коенды. Азат абый да спортны үз итә. Хәзер “Батыр” спорткомплексына баралар, анда ныклап шөгыльләнәләр. Миңа уңышка ирешүдә тренерыбыз Даутов Ришат Гөмәрович үзенең киңәшләре белән даими ярдәм итеп тора. Рәхмәт аңарга.

-Нинди спорт төрләрен яратасың?

-Кул көрәше, волейбол.-Нинди уку йөртына керергә телисең?

-Шәфкать туташы буласым килә.

-Укучыларга теләкләрең бармы.

-Спортны яратсыннар. Торыш әдәпле булсыннар, кешеләрне, җанварларны кыерсытмасыннар, мәрхәмәтле булсыннар.

-Гөлшат җавапларың өчен рәхмәт. Синең  барлык хыялларың тормышка ашсын. (Кем белә, бәлки безнең Гөлшатыбыз  әле армспорт буенча чемпион да булыр.Бирсен Ходай)



















| Гамәлгә куючы – ТР Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп белем бирү мәктәбе | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| E-mail - mkibiakozi40mail.ru | Тел.:8(84360)56-2-40 | 422080 Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибяхуҗа авылы, Малая урамы, өй № 10 | Тираж сертификацияләнмәгән Тираж 10 данә | Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел | Газета айга бер тапкыр чыга |